ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 август 2018 ел № 4481

Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге
5793 нче карары белән расланган 2017-2019 елларга
Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль
ярдәм күрсәтүнең муниципаль программасына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ЗРТ санлы Закон, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының өстәмә социаль ярдәм чаралары һәм аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүгә хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 нче карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 нче карары белән (Башкарма комитетның 2017 елның 10 мартындагы 1182 нче, 2017 елның 14 апрелендәге 2234 нче, 2017 елның 24 июлендәге 4318 нче, 2017 елның 25 сентябрендәге 5702 нче, 2017 елның 27 сентябрендәге 5755 нче, 2017 елның 23 ноябрендәге 7195 нче, 2017 елның 7 декабрендәге 7601 нче карарлары редакциясендә) расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтүнең муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 бүлекнең II бүлекчәсендә «Бәйрәм һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү»:

1 пунктта «2018 ел (мең сум)» баганасындагы «112,0» цифрларын «104,0» цифрларына алмаштырырга;

«Барлыгы» дигән юлда «2018 ел (мең сум)» баганасындагы «890,0» цифрларын «882,0» цифрларына алмаштырырга.

2) 7 бүлекнең III бүлекчәсендә «Ветераннарга, инвалидларга һәм инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча чараларны тормышка ашыру»:

1 пунктта «2018 ел (мең сум)» баганасындагы «300,00» цифрларын «294,0» цифрларына алмаштырырга;

2 пункттагы чара исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Ветераннарны, инвалидларны һәм инвалид балаларны социаль һәм мәдәни тернәкләндерү буенча чараларны физик культура һәм спортка бәйләп үткәрү»;

«Барлыгы» дигән юлда «2018 ел (мең сум)» баганасындагы «2829,0» цифрларын «2823,0» цифрларына алмаштырырга.

3) 7 бүлекнең IV бүлекчәсендә «Аз керемле балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча чараларны тормышка ашыру»:

1 пунктта «2018 ел (мең сум)» баганасындагы «1000,00» цифрларын «1014,0» цифрларына алмаштырырга;

«Барлыгы» дигән юлда «2018 ел (мең сум)» баганасындагы «1852,0» цифрларын «1866,0» цифрларына алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин